**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңа Чүпрәле авылында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**26 нчы ноябрь 2024 ел** **Яңа Чүпрәле** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Иске Чүпрәле авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Яңа Чүпрәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 59/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2024 елның 26 ноябрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2024 елның 26 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 832 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны - 488, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 58,65 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 488 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» Яңа Чүпрәле торак пунктында гражданнар җыенын 2024 елның 26 ноябрендә узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Яңа Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү» ярдәмче программасы кабул ителде.

3. 2025 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Яңа Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

4. Үзара салым акчаларын түләүдән азат итү:

1) 18 яшькә кадәрге өч яки аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), тулы Дәүләт тәэмин ителешендә булган балаларны исәпкә алмаганда;

3) махсус хәрби операциядә катнашучылар;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары(хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр);

5) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүче) хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларына.

5. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә кирәк: Яңа Чүпрәле авылы, Яшьләр урамы, 17 нче йорт, Иске Чүпрәле башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы бинасында , Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы,
Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары,
халык җыенында рәислек итүче: Р.Д.Низамов